

НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

# УРМАН КЫЗЫ

(ПОЭМА)

**Сафиулла ӘҺЛИУЛЛИН**
**Иске Мөъмин авылы,**
**Әсәкәй районы.**

**(Дәвамы. Башы 6 -7 нче саннарда).**

## Дүртенче бүлек

Илдә сугыш башланганын
Белмәделәр күбесе.
Базар эче гөрләп тора,
Көн матур бүген, эссе.

Төш вакыты җиткәч кенә
Радиодан хәбәр бирделәр.
Немец сугыш башлаганын
Шунда гына белделәр.

Бу хәбәрдән күбесенең
Кулы эшкә бармады.
Сугышның тиз бетмәгәнен
Бөтен халык аңлады.

Сугыш монда килгәчәге
Көн кебек ачык иде.
Бөркен шулай бу авылга
Машина килеп керде.

Аңа солдатлар төялгән,
Барысы яшел киемнән.
Һәрберсенең иңбашына
Автоматлар эленгән.

Сәлеп алган солдатлары
Өй буенча йөрделәр.
Өй аралаш капкаларга
Белдерүләр элделәр.

Авылның күп егетләре
Урман эченә качтылар.
Флаг элеп шул мәктәптә
Комендатура ачтылар.

Авыл халкы өчен яңа,
Сәер тормыш башланды.
Кем карышты, кәпә-көндез
Йорты утырып янды.

Гөнаһсызга атылган
Чаклар да булгалады.
Каберләре үрнәк өчен,
Йортсыз, малсыз да калды.

## Бишенче бүлек

Урман хуҗасы да йокысыннан
Соңга калып кына уянды.
Мал-туарын куып, кош-кортына
Келәтеннән алып җем салды.

Кызы торып, кулын, битен югач,
Тәмләп кенә чәйне эчтеләр.
Чәчкә алып, ашыкмый гына
Хатын каберенә киттеләр.

Менә зират, тирә-ягы уратылган.
Ерак түгел, урман читендә.
Үлгәннәрнең каберен тазартырга
Якыннары килеп йөри еш кына.

Урман хуҗасы да кызы белән,
Кабер өстенә чәчкә сиптеләр.
Бераз торгач, күз яшьләрен сөртеп
Кайту ягына чыгып киттеләр.

Көн авышкан, бик эссе дә түгел,
Халык кайтып килә базардан.
Бүген менә сугыш башланганын
Ишеттеләр алар шулардан.

**(Дәвамы киләсе санда)**

ИСЛАМ

# ЯХШЫ СҮЗ

**Күркәм холыклар турында сүзебезне дәвам итәбез. Бүгенге тема яхшы сүз турында**

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.): «Берәү Аллаһы Тәгаләгә һәм ахирәт көненә ышанса, күркәм сүзләр генә сөйләсен, күркәм сүзләр сөйли алмаса, дәшми торсын», — ди. Икенче бер хәдисендә: «һәр яхшы сүз — сәдака», -дип белдерде.

Дин нигезенең беренче өлеше — иман китерү, ышану булса, икенче өлеше — гыйбадәт (Аллаһ кушканнарын үтәү, тыйганнарыннан тыелу), өченче өлеше — күркәм холык. Аллаһны хакыйкый тану белән, тануыбыз безне гыйбадәткә этәрә. Чөнки, иманлы кешегә намаз уку, руза тоту, зәкят бирү, хаҗ кылу, хәрамнардан тыелу авыр түгел. Ул боларны үтәүдән чын рухи тәм, ләззәт таба. Аллаһ кушканнарны үтәү, тыйганнарыннан тыелу- күңелне сафландыра, кальбне пакьли. Ә инде ихлас, саф күңелдән матур сүзләр генә чыга ала. Күркәм холыкның үлчәве, билгесе — кешеләр арасындагы мөгамәлә. Бүген, без, бу мәсьәләдә үз-үзебезне ничегрәк тотабыз соң, бер-беребезгә нинди сүзләр әйтәбез? Әйткән сүзләребездә мизанга куелачак. Ул көнне инде кирәкмәгән сүз, ялган, гайбәт, начар сүзләр сөйләүгә караганда дәшми торуның никадәр кыйммәтле икәнен аңларбыз. Шуның өчен дә бит халыкта: «Сөйләвең көмеш булса да, дәшмәвең алтын», — диләр.

«Кыямәт көнендә гөнаһы иң күп булган кеше — дөньяда вакытта әһәмиятсез сүзне күп сөйләгән кеше».

Теле тарафыннан адәм баласына бик зур хәтәрләр киләчәк булганлыктан, Рәсүллуллаһ мөмкин кадәр телне тыю хакында өммәтен үгетли һәм юк-бар сүз белән гомер үткәрмәскә нәсыйхәт итә. Телне иркен кую ялган һәм хата, гайбәт һәм яла, рия һәм күз буяу, фәхеш һәм дошманлык, җәбер һәм золым кебек афәтләргә сәбәп булганлыгы өчен:

«Эндәшмәгән — котылган», — диелә.

Аллаһ Раббыбыз: «Әти-әнигә «уф» дип тә әйтмәгез», -дип безне кисәткән. Әти-әнигә карата да матур сүзләрне сирәк кулланабыз. Без әле чит кешеләр янында үзебезне күпмедер дәрәҗәдә кысада тотарга тырышабыз, авызны «чамалап» ачабыз, әмма гаиләдә чама югала, ир хатынына, хатын иренә, каенана килененә, килен каенанасына, улы атасына, атасы улына нинди сүзләр генә әйтми. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.): «Сәдаканы башта үзеңә, аннан гаиләңә, аннан башкаларга бир», — дигәнен, «Иң элек үзең күркәм сүзләр сөйлә, өй җәмәгатеңә күркәм мөгамәләдә бул, башкалар янында да күркәм сүзләр сөйлә», — дип тә аңларга кирәк. Чөнки һәр яхшы сүз — сәдака.

**(Дәвамы киләсе санда)**

**Имам ИЛДАР хәзрәт,**
**Әсәкәй мәчете.**

# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ



(время местное, летнее)

| МАЙ | Фаджр Иртә | Восход Кояш чыга | Зухр Ойлә | Аср Икенде | Магриб Ахшам | Иша Ясту |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 5-56 | 6-56 | 15-10 | 20-04 | 22-04 | 23-34 |
| 2 | 5-54 | 6-54 | 15-10 | 20-06 | 22-06 | 23-36 |
| 3 | 5-52 | 6-52 | 15-10 | 20-08 | 22-08 | 23-38 |
| 4 | 5-50 | 6-50 | 15-10 | 20-10 | 22-10 | 23-40 |
| 5 | 5-48 | 6-48 | 15-10 | 20-12 | 22-12 | 23-42 |
| 6 | 5-46 | 6-46 | 15-10 | 20-13 | 22-13 | 23-43 |
| 7 | 5-44 | 6-44 | 15-10 | 20-15 | 22-15 | 23-45 |
| 8 | 5-42 | 6-42 | 15-10 | 20-16 | 22-16 | 23-46 |
| 9 | 5-40 | 6-40 | 15-10 | 20-18 | 22-18 | 23-48 |
| 10 | 5-38 | 6-38 | 15-10 | 20-20 | 22-20 | 23-50 |
| 11 | 5-36 | 6-36 | 15-10 | 20-21 | 22-21 | 23-51 |
| 12 | 5-33 | 6-33 | 15-10 | 20-23 | 22-23 | 23-53 |
| 13 | 5-31 | 6-31 | 15-10 | 20-25 | 22-25 | 23-55 |
| 14 | 5-30 | 6-30 | 15-10 | 20-26 | 22-26 | 23-56 |
| 15 | 5-29 | 6-29 | 15-10 | 20-28 | 22-28 | 23-58 |
| 16 | 5-28 | 6-28 | 15-10 | 20-30 | 22-30 | 24-00 |
| 17 | 5-26 | 6-26 | 15-10 | 20-32 | 22-32 | 24-02 |
| 18 | 5-24 | 6-24 | 15-10 | 20-34 | 22-34 | 24-04 |
| 19 | 5-22 | 6-23 | 15-10 | 20-35 | 22-35 | 24-05 |
| 20 | 5-21 | 6-21 | 15-10 | 20-37 | 22-37 | 24-07 |
| 21 | 5-20 | 6-20 | 15-10 | 20-38 | 22-38 | 24-08 |
| 22 | 5-18 | 6-18 | 15-10 | 20-40 | 22-40 | 24-10 |
| 23 | 5-17 | 6-17 | 15-10 | 20-41 | 22-41 | 24-11 |
| 24 | 5-16 | 6-16 | 15-10 | 20-43 | 22-43 | 24-13 |
| 25 | 5-15 | 6-15 | 15-10 | 22-44 | 22-44 | 24-14 |
| 26 | 5-14 | 6-14 | 15-10 | 22-45 | 22-45 | 24-15 |
| 27 | 5-12 | 6-12 | 15-10 | 20-47 | 22-47 | 24-17 |
| 28 | 5-11 | 6-11 | 15-10 | 20-48 | 22-48 | 24-18 |
| 29 | 5-10 | 6-10 | 15-10 | 22-50 | 22-50 | 24-20 |
| 30 | 5-09 | 6-09 | 15-10 | 22-51 | 22-51 | 24-21 |
| 31 | 5-08 | 6-08 | 15-10 | 20-52 | 22-52 | 24-22 |

**Данные предоставлены Бугурусланским муфтиятом.**
**Возможна разница во времени в сравнении с другими источниками, на 3-5 минут.**